Россия Банкы гражданнарны финанс мошенникларыннан яклау буенча гамәлдәге законнарны ка-милләштерvдә актив катнаша.

2025 елда берничә моhим яналык vз кочене керде. Аларнын ничек эшләвен тикшерербез.
Кредитлар hәм заемнар бирvгә vз-vзенне тыю 2025 елнын 1 мартыннан барлык теләvчеләр кредитлар hәм займнар бирvгә vз-vзен тыюны билгели ала. Ул кешеләрнен шәхси мәгълvматларын урлаган hәм законсыз рәвештә кредитлар hәм займнар рәсмиләштергән мошенниклардан сакланырга ярдәм итә.
Үзенне hәм якыннарынны мошенниклардан саклау очен тагын бер момкинлек бар - «икенче кул» сервисы. Бу нәрсә дигән сvз? Банк операцияләрен контрольдә тотуны хәзер туганына яки дустына ышанып тапшырырга момкин. Якын кешеләрнен, әгәр алар шикле булып кvренсә, акча кvчерvләрне расларга яки кире кагарга хокукы булачак. Механизм кvчерvләргә, шул исәптән банк карталарын кулланып, тиз тvләvләр системасы аша кvчерvләргә hәм акчаларны алуга кагыла. Шул ук вакытта кеше ярдәмчесе vзе беләнбергә нинди операцияләрне тикшерәчәген vзе сайлый. Моhим момент - ярдәмченен исәп-хисапка керv момкинлеге hәм анын буенча мостәкыйль опе-рацияләргә хокукы булмаячак. Мондый чара мошенниклардан аеруча зәгыйфь гражданнарны, беренче чиратта олкән яшьтәге кешеләрне якларга момкинлек бирәчәк. Сервис шулай ук яшvсмерләрнен кv-черvләренә ата-аналар контролен кочәйтергә ярдәм итәчәк, алар еш кына дропперлык схемаларына жә-леп ителәләр (жинаять юлы белән алынган акчаларны чыгару hәм кулга алу), барлык момкин булган тискәре нәтижәләрне анламыйча.
Сервис болайрак эшли: операцияне раслау яисә кире кагу очен хәбәр ителгәннән сон 12 сәгать бирелә; сервисны тоташтыруны клиент vзе генә тәкъдим итә ала; хезмәтне тоташтыру ысулын hәр банк мостәкыйль билгели; әгәр клиент хезмәт кvр-сәтvдән баш тартса, банк аны 24 сәгать эчендә сvндерәчәк. Мондый вакытлы тәнәфес мошенниклар йогынтысында «икенче кул» сервисын сvн-дерv куркынычын киметv очен кирәк. Куллану кредитлары hәм заемнары буенча «суыну чоры.»
2025 елнын 1 сентябреннән 50 меннән 200 мен сумга кадәр кредит яки займ буенча акчаны тиешле килешvгә кул куйганнан сон 4 сәгать узгач алырга момкин. Әгәр сумма бу бусагадан артса, акчалар 48 сәгатьтән дә иртәрәк кvчерелмәячәк. Бу вакыт эчендә кеше, әгәр мошенниклар йогынтысында булса, куркынычларны vлчи hәм vз карарын vзгәртә алачак. Заемщикнын шул чоры вакытында туганнары, якыннары белән кинәшергә, анына килергә олгерvе ихтимал; финанс нәтижәләреннән башка кулланучылар кредиты яки займ алудан баш тартырга момкин. Монын очен банкка яки МФЦга баш тарту турында килешvдә кvрсәтелгән ысул белән хәбәр итәргә кирәк.

Н.ХӘЛИЛ әзерләде